**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Важашур авыл җирлеге башлыгы**
**карары**

**2023 елның 10 ноябре** **№ 5**

**«Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлегенең Важашур авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2023 елның 21 ноябренә 13.00 сәгатькә Кукмара муниципаль районының Важашур авыл җирлеген Важашур авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә. Гражданнар җыенын Починок Сутер авылы, Яшьләр урамы, 1д йорты адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Важашур авыл җирлегенең Важашур авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге 4 һәм аннан да күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрдән; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәклардән; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Важашур авылының Киров, Сахалин, Яшел (Зеленая) урамнарында вак таш җәеп, юллар төзү һәм ремонтлау; проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Важашур авылында юлларны җәен һәм кышын карап тоту һәм чистарту, проект-смета документлары;
- Важашур авылы Киров, Яшел урамындагы су челтәрләрен карап тоту, ремонтлау һәм урнаштыру, проект-смета документлары;
- Важашур авылында урам яктырткычларын ремонтлау һәм сатып алу, проект-смета документлары?

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Гражданнар җыенын үткәрүгә җаваплы итеп Важашур авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм җирлекнең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Җирлек башлыгы П.Л. Иванов